РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

12.11.2021 | Буа шәһәре | № 3-20

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Кушымта итеп бирелә торган карта-схема нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен Түбән Наратбаш, Татар Буасы һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләренә кергән җир кишәрлекләрен «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенә кертү юлы белән үзгәртү инициативасы белән чыгарга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына тиешле муниципаль берәмлекләрнең чикләрен тәкъдим ителә торган үзгәртү буенча фикер белдерүне тәкъдим итәргә.


3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе Р.Р. Камартдинов

ТР Буа муниципаль районы Советының
«12» ноябрь 2021 елның 3-20 номерлы
карарына кушымта

## Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- Буа муниципаль районы чиге
- Муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Түбән Наратбаш авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- В-Г - Ырынгы авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Г-Д - Татар Буасы авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Җирлекләрнең административ үзәкләре
- Торак пунктлар
- Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Ырынгы авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе